Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Большенуркеевского сельского
поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районының Зур Нөркәй
авыл җирлеге
Башкарма комитеты

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«19» сентябрь 2025 ел

КАРАР
№ 16

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге муниципаль берәмлеген 2035 елга кадәр су белән тәэмин итү, су чыгару схемасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль канун, «су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 07.12.2011 ел, № 416-ФЗ Федераль канун, РФ Хөкүмәтенең 05.09.2013 ел, N 782 карары (24.04.2025 ел редакциясе) нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының "Зур Нөркәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитеты карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеген 2035 елга кадәр чорга су белән тәэмин итү схемасын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешнен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе

Ә.Н.Сабитов